# Чишмә башы «Якты юл»да

"Ләйсән" әдәби берләшмәсенең 60 еллыгына чакырылгач, ничектер, күңел кузгалды. Бәлки хикмәт шундадыр, күп еллар китапханәче булып эшләү дәверендә мин якташ язучыларның иҗатына бик күп кичәләр, каладан язучыларны чакырып, очрашулар үткәрдем. Танылган шагыйрь Рәшит Гәрәй безнең Күзкәй мәктәбендә белем алган, ул әлеге әдәби берләшмәнең утырышларында еш катнашып, каләм тибрәтүче яшьләрнең иҗаты белән танышып, уңышлыларын республика матбугаты, район газетасы битләрендә чыгарган. Кыска гына гомерендә онытылмаслык шигырьләр, җырлар калдырып киткән шагыйрь Фәннур Сафин безнең авыл егете. Ул да шушы берләшмәнең утырышларында актив катнашып шигърият мәктәбе үткән. Без үзебезнең "Хәтирә" клубында, укучылар белән бергәләп, аның туган көнендә ел саен әдәби кичә үткәрәбез.

Мәктәптә укыганда ук шушы әдәби берләшмәгә йөргән Мөдәррис Әгъләмов, Разил Вәлиевларның юбилейларына, иҗатларына багышланган күпме әдәби кичәләр үткәрдем һәм, билгеле инде, иҗатларының чишмә башы район газетасына килеп тоташа иде. Шулар барысы, кино тасма-



Тукай районы китапханәчеләре. / АВТОР ФОТОСЫ.

Бүген 60 еллык юбилеен уздыра торган әдәби берләшмә "Коммунизм байрагы"дип аталган район газетасында оешканын беләм. Ул хакта безгә авылдашыбыз, ветеран журналист Заһидә апа Нәбиуллина сөйли иде. Шәһәрдә зур төзелешләр башлангач, «Коммунизм байрагы» газетасы юкка чыккан, ә аның иҗат коллективы тулы составта төбәктә саф татар телендә чыга башлаган "Якты юл" газетасы редакциясенә күчкән. Ул зур горурлык белән: «Чынында әдәби берләшмәнең чишмә башы "Якты юл" газетасында саклан-

көчләр килә башлагач, ул Язучылар оешмасы канаты астына күчте»,-дия иде. Заһидә апа күп еллар шушы әдәби берләшмәнең секретаре булган. Һәр язучы турында сәгатьләр буе сөйли ала. Ә мин күп еллар буе шул газетаның актив авыл хәбәрчесе буларак, вазифам да шундый бит, шәһәр-районның әдәбият дөньясы белән хәбәрдар булырга, шигырьләр язмасам да, кыска хикәяләр, авыл эшчәннәре турында зарисовкалар язып, язучыларның иҗатына багышланган кичәләр үткәреп, төбәгебезнең әдәби дөньясында кайнап яшәр-

"Ләйсән" әдәби иҗат берләшмәсенең бүгенге җитәкчесе Чаллы шәһәренең Үзәк китапханәсе хезмәткәре, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Роза Хәмидуллина үткәргән чараларда булганым бар һәм аннан һәрвакыт эштә кулланырлык яңалык алып кайтам. Бу юбилей кичәсен дә, дәрәҗәсенә җиткерерлек итеп, бик матур оештырган. Сәхнәгә берләшмәдә канат ныгыткан, инде күбесе үз китапларын чыгарган, иҗатта үз урыннарын тапкан авторларны чакыра. Роза Галимулловнаның җылы сүзләр әйтеп Рәхмәт хатлары, Күкрәк билгеләре тапшыруын залдагылар алкышларга күмәләр. Әйтерең юк, рухландыргыч, күңелле мизгелләр. Күп кенә шигырьләр авторы, коллегабыз Калмия авылы китапханәчесе Энҗе Галиәхмәтова да берләшмәнең Рәхмәт Хатына лаек булды. Ул үзенең очрашуга махсус язган "Китап" шигырен бик матур итеп сөйләде.

Авылларда үткәрелә торган чараларга яратып йөри торган Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, шагыйрә Зөләйха Минһаҗеваның чыгышы безнең, район китапханәчеләренең күңеленә сары май булып ятты.

- Залда Тукай районы китап-

кешеләренә мин аеруча рәхмәтле. Менә шушы залга җыелган язучыларның иҗаты җимешләрен сез халыкка җиткерүчеләр. Китапханәче ул укучы белән язучы арасына алтын күпер салучы. Ә залдагы берләшмә әгъзалары исә, ләйсән яңгыр кебек, халыкның рухын чистартучылар. Бүгенге тынгысыз дөньяда сезнең хезмәтегез аерым урын алып тора.",- диде ул.

Тукай районының танылган шагыйрәсе Рәзинә Сәетгәрәева дә авыл китапханәчеләренә ихлас рәхмәтен белдерде. «Авыл китапханәләренә очрашуларга гел чакырып торасыз. Сез безне халык белән очраштырып, иҗатка илһам бирәсез. Китапханәдә авыл кешеләре белән очрашып сөйләшү күңелгә яңа сулыш бирә»,- диде ул.

Юбилей бәйрәменең тагын бер күңелле мизгеле -алдынгыларга бик матур итеп, махсус эшләнгән "60 лет ЛИТО "Лейсян" ("Ләйсән" берләшмәсенә 60 ел) дигән күкрәк билгесе тапшыру булды. Ахырдан Роза Хәмидуллина авыл китапханәләре хезмәткәрләренә Яңа ел күчтәнәче итеп 800 дәнә татар язучыларының китабын тапшырды.

**Тәнзилә Шәйхнурова,**
**Күзкәй китапханәсе мөдире**